# КАРАР
# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы

Азнакай шәһәре № 153-37 «26» ноябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (15.06.2015 №170-47, 21.10.2015 №10-2, 28.05.2018 №99-26, 12.11.2018 №114-28, 13.12.2018 №119-29, 23.05.2019 №138-33 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 143-41 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» (15.06.2015 №170-47, 21.10.2015 №10-2, 28.05.2018 №99-26, 12.11.2018 №114-28, 13.12.2018 №119-29, 23.05.2019 №138-33 карарлар редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 1 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары»;

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басма - «Маяк» газетасында басылып чыкканнан соң бер ай узгач та үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин